СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д. 13, д.Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яшьләр урамы, 13 йорты, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366)53-4-32, факс (84366)53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Советы карары**

**01 июля 2024 ел** **№ 84**

**«Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләрнең хезмәт хакы күләме һәм шартлары турында» 2024 елның 4 июнендәге 82 номерлы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 06 маендагы 300 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Татарстан Республикасында депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге уставы нигезендә, Урта Курса авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләрнең хезмәт хакы күләме һәм шартлары турында» 2024 елның 4 июнендәге 82 номерлы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларга хезмәт хакы түләү турында Нигезләмәнең 4 пунктын (2 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлау коэффициентлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| | **Вазыйфа исеме** | **Коэффициент** |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе | 1,37 |
| | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (секретарь) | 1,33 |
| | Әйдәп баручы белгеч | 1,11 |
| | 1 категорияле белгеч<br>2 категорияле белгеч<br>белгеч | 1,00 |

2. Әлеге карар 2024 елның 01 июленнән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина

СОВЕТ СРЕДНЕКОРСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609003070